ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.04.2021 ел. — с. Майдан — №11

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегендә
кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү буенча
Координация советын төзү турында

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007нче елның 24нче июлендәге 209-ФЗ Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003нче елның 6нчы октябреннән131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү буенча Координация Советы төзергә (1нче кушымта) .

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү буенча Координация Советы турында Нигезләмәне расларга (2нче кушымта).

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы — В. В. Михеев

Мәйдан авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021нче елның 29нчы
апреленнән 11нче карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү буенча Координация Советы СОСТАВЫ

Михеев Виктор Викторович - Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башлыгы, Координация Советы рәисе;

Яманова Наталья Викторовна - Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советы депутаты, Координация Советы рәисе урынбасары;

Гусева Раиса Владимировна - Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре, Координация Советы секретаре;

Нуруллина Ирина Николаевна - шәхси эшмәкәр (килешү буенча).

Мәйдан авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021нче елның 29нчы
апреленнән 11нче карарына
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү буенча Координация Советы турында Нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә "Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007нче елның 24нче июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү буенча Координация Советы (алга таба - Координация Советы) базар икътисады шартларында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең стратегик юнәлешләрен билгеләү максатларында авыл җирлеге башкарма хакимияте органнарының, иҗтимагый оешмаларның һәм эшкуарлык даирәләре вәкилләренең эш-гамәлләрен консультацияләүне тәэмин итә торган даими эшләүче консультатив-киңәшмә органы булып тора.

Координация Советы юридик зат булып тормый һәм үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

Координация Советы үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

Координация Советы үз эшчәнлегендә дәүләт хакимияте органнары, районның җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар һәм эшмәкәрлек структуралары белән хезмәттәшлек итә.

## II. Төп бурычлар

Координация Советының төп бурычлары булып торалар:

- Дәүләт икътисадый сәясәтен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- җирлектә кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме һәм аны үстерүнең принципларын, стратегияләрен, өстенлекле юнәлешләрен эшләү;
- кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итүгә һәм аны үстерүгә юнәлдерелгән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү;
- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең максатларын һәм бурычларын, уңай тәҗрибәсен пропагандалау.

## III. Функцияләре

Төп бурычлар нигезендә Координация Советы түбәндәге функцияләрне башкара:

- җирлектәге кече һәм урта эшмәкәрлек торышы мониторингының нәтиҗәләрен карый;

- авыл җирлеге башлыгына кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү стратегиясе һәм тактикасы буенча тәкъдимнәр кертә;

- инвестицияләр, алдынгы технологияләр һәм идарә итү тәҗрибәсен җәлеп итү һәм куллану буенча тәкъдимнәр эшли;

- Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлык мәнфәгатьләренә турыдан-туры кагылучы Республика законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларына экспертиза оештыра, эшкуарлык эшчәнлегенең төрле мәсьәләләрен җайга салучы гамәлдәге законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

- проектларны карый һәм кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча республика программаларының үтәлеше барышын анализлый;

- кече һәм урта эшкуарлыкның әһәмиятен арттыруга юнәлдерелгән мәгълүмати мохит булдыруга, эшкуарлык инициативасын үстерүгә, эшкуарларны икътисадый формаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру процессына җәлеп итүгә ярдәм итә.

## IV. Хокуклары

Координацион Совет төп бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Советының кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән карар проектларын әзерләүдә катнашырга;

- башкарма хакимият органнарыннан, хуҗалык итүче субъектлардан Координация Советы эше өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

- кирәк булганда, билгеләнгән тәртиптә консультантлар сыйфатында тиешле белгечләрне җәлеп итәргә;

- конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эшче төркемнәр булдырырга һәм әлеге төркемнәрнең эш тәртибен билгеләргә;

- җирлектә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүнең актуаль проблемалары буенча аналитик язмалар әзерләргә.

## V. Эшчәнлек оештыру

Координация Советын Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге башлыгы җитәкли. Координация Советы составына авыл җирлеге башкарма хакимияте органнары вәкилләре һәм иҗтимагый берләшмәләрнең тиешле органнары тарафыннан билгеләнә торган кече һәм урта эшкуарлык вәкилләре тигез нигезгә керә. Координация Советы утырышлары аның рәисе раслаган эш планы нигезендә, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Координация Советы утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Утырышның көн тәртибе, шулай ук аны уздыру вакыты һәм урыны турында мәгълүмат Координация Советы әгъзаларына утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча җибәрелә. Координация Советы карарлары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Координация Советы рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Координация Советын бетерү Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән башкарыла.